**5 нче сыйныф**

**Татар әдәбиятыннан тест**

**Татар халык әкияте «Үги кыз»**

**1.«Үги кыз» әкиятенең берничә варианты бар. Сез дәреслектән кайсы әкиятне укыдыгыз? Өзекләрне укып билгеләгез.**
а) Кыз сандыкны алып, атына атланып, сыерны җитәкләп, сарыкларын, кәҗәләрен ияртеп, әбигә рәхмәт әйтә-әйтә, юлга чыгып китә.
ә) Хәзер сихерче карчык кызның артыннан куа чыккан. Артыннан җитеп барганда, кыз сөлгене ташлаган. Сөлге зур күл булган.
б) Кыз: «Нәрсә генә әйтим икән инде, бөтен әйберем дә булды бит», — дип уйланып торганда, таң әтәче кычкырып җибәрә дә, әтәч тавышын ишетүгә, карчык юкка чыга.
**2.Үги кылны урманга кем илтә?**
а)әтисе;
ә)агасы;
б) үги әнисе.
**3.Агасы кызны ничек хәйләли?**
а)качып китә;
ә) зур агачка утын тукмагы асып куя;
б) кызны көтеп тора.
**4.Кыз нинди көтүләргә очрый?**
а) ат, сыер, сарык, кәҗә көтүенә;
ә)сыер, каз, сарык көтүенә;
б) кәҗә, дуңгыз, үгез көтүенә.
**5.Убырлы карчык кызны ничә мәртәбә сынап карый?**
а) биш мәртәбә;
ә)дүрт мәртәбә;
б) өч мәртәбә.
**6.Карчык кызга нинди сандык бирә?**
а) яшел сандык;
ә) кызыл сандык;
б) кара сандык
**7.Үги ана ни өчен үз кызын да урманга җибәрә?**
а) баерга уйлый;
ә) үги кыздан көнләшә;
б) ачуы килә.
**8.Убырлы карчык ни сәбәпле бу кызга кара сандык бирә?**
а) кыз әбине орыша;
ә) күргән һәр урыннан алтын урлый;
б) ялганлый.
**9.Үги ананың үз кызы ничек үлә?**
а) кара елан буып үтерә;
ә) үзе үлә;

б) агалары үтерә.

**10. Мәкальләрнең кайсысы шушы әкияткә туры килми?**

а) Чокырны үзеңә дип казы.

ә) Бала яхшы булса — дәүләт, яман булса — имгәк.

б) Үги үз булмый, колак күз булмый.

**Ачкыч**

1. А
2. Ә
3. Ә
4. А
5. Б
6. А
7. А
8. Ә
9. А
10. А

## Бәяләү

## 9-10 балл – “5”ле

## 7-8 балл – “4”ле

## 5-6 балл – “3”ле